

АЙ БЕЛӘН КОЯШ

ИҢ ОЗЫН ӘКИЯТ

ХУҖА ШАРДЫН ХӘЙЛӘСЕ

ЭНҖЕ БӨРТЕГЕ



ИҢ ОЗЫН ӘКИЯТ

ДӨНЬЯ ХАЛЫКЛАРЫ ӘКИЯТЛӘРЕ

ТАВИЛ ХАҖИӘХМӘТОВ
рәсемнәре

КАЗАН. ҖЫЕН ФОНДЫ
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
1994



ПАДИШАҺ ҺӘМ АГАЙ



ХӘЙЛӘКӘР ЭТӘЧ



МАЙМЫЛ БЕЛӘН ЧИКЕРТКӘ



КАБАРТМА



ИҢ ОЗЫН ӘКИЯТ

Француз
халык әкияте



Яшәгән, ди, бер король. Булган, ди, аның бик тә акыллы әкиятчесе. Һәр кичне әкият тыңламаса, король йокыга китә алмый икән.

Шулай бер кичне, гадәттәгечә, йоклар алдыннан король әкиятчесен чакырып китергән. Әкиятче, көне буе король балаларына мәзәкләр сөйли-сөйли алҗып, йокларга яткан икән.

— Король галиҗәнаплары,— дип, күзләрен уауа сүз башлаган ул,— вакыт бик соң бит инде. Йокларга кирәк. Әкият качмас, теләсәгез, иртәгә сөйләрмен.





Корольнең моңа ачуы чыккан. Ул, аяк тибеп, өр-яңа әкият сөйләргә әмер биргән.

— Бу әкиятең дөньядагы иң озын әкият булсын! Ике йөз кич рәттән сөйләрлек әкият чыгармасаң, башыңны кистерәм! — дип җикеренгән король.

— Яшәгән, ди, бер кеше, булган, ди, аның йөз алтыны,— дип башлаган әкиятчесе.— Йөз алтынга ул ике йөз сарык сатып алган да аларны чыбыркы белән куалап алып кайтып киткән. Кайта торгач, елга ярына килеп җиткәннәр. Язгы ташудан елга җәеләп, болыннар су астында калган, ә якынтирәдә бер күпер дә юк икән. Нишләргә? Ары



чапкан, бире чапкан агай һәм, эзли торгач, яр буенда бер көймә тапкан. Ләкин көймә бик кечкенә, сыйса аңа бары бер сарык кына сыярлык, ди...

— Шуннан, шуннан? Шуннан нәрсә булган? — дип җикергән король.— Бер сарыкны көймәгә салып алып чыккан, ди... Ә калган сарыкларны нишләткән?

— Король галиҗәнаплары,— дип, мыек астыннан гына елмайган әкиятче.— Елга бик киң, көймә бик бәләкәй, ә сарыклар би-ик күп — ике йөз! Бер сарыкны каршы ярга чыгару өчен бер төн вакыт кирәк. Әйдәгез, көймә кире әйләнеп килгәнче без йоклый торыйк. Ә иртәгә тагын бер сарыкны чыгарырбыз. Шулай итеп, ике йөз сарыкны теге ярга чыгарып бетергәнче мин һәр кичне бу әкиятнең дәвамын сөйләрмен.



АЙ БЕЛӘН ҚОЯШ

Татар
халык әкияте



Ай белән Қояш элек заманда гел бер җирдә генә тормакчы булганнар. Шуннан соң, бөтен кошларны җыеп, шул турыда җыелыш ясаганнар. Бөтен кошлар, боларның бер җирдә торуларына риза булып, шуңа кул куйганнар.

Болар арасында бары бер генә кош кул куймыйча калган, ди. Ул булган Ярканат. Бүтән кошлар Ярканаттан сораганнар:

— Бөтен кошлар кул куйганда, нилектән син генә кул куймадың? — дигәннәр.







— Қулны мин шул сәбәпле куймадым,— дигән Ярканат,— Қояш белән Ай бер җирдә генә торсалар, җил бер генә яктан исәр, агачлар кәкре булып үсәрләр, игеннәр дә Қояш төшкән җирдә генә үсәр, Қояш төшмәгән җирдә үсмәс иде.

Шуннан соң бүтән кошлар әйткәннәр:

— Дөрес әйтә шул, Қояш төшмәгән җирдә иген үсми инде ул,— дигәннәр.

Ай белән Қояшның икесенә дә, бер җирдә тормаска, әйләнеп йөрергә, дип карар чыгарганнар, ди.

Шуннан соң Қояш әйткән Ярканатка:







— Мин сине үземнең яктылыгымда йөртмәм,— дигән.

Менә ни өчен Ярканат көн яктысында чыгып йөри алмый икән!

Аңа Ай сүз әйтмәгән, шуңа күрә ул Ай яктысында бик әйбәт йөри, ди.

Ай белән Қояшның болай әйләнеп йөрүен бөтен кош-кортлар, бөтен халыклар бик дөрес дип кабул иткәннәр, имеш. Шуннан соң игеннәр дә яхшы була башлаган, ди.

ХУҖА ШАРДЫН ХӘЙЛӘСЕ

Абхаз
халык әкияте



Хуҗа Шардын атлы бик мәзәк бер кеше үзенең күршесе белән елга яры буйлап бара икән. Бара торгач, боларның каршысына кача-поса килүче җайдак очраган. Җайдак алдыннан мәһабәт гәүдәле үгез бара икән. Шардын моның урланган үгез икәнен шунда ук сизенгән. Ул бер чүәген салган да юл уртасына ташлап калдырган, ә үзе куаклар артына кереп поскан. Җайдак чүәкне еракган ук күреп алган һәм, атыннан сикереп төшеп, үгезне агачка бәйләп куйган. Аннары атына



атланып, чүәкнең икенче сыңарын эзләргә киткән.

Шуны гына көтеп торган Шардын күршесе белән үгез янына йөгергән. Үгезне тиз генә бәйдән ычкындырганнар да урманга алып кереп суйганнар болар. Башын елгага ташлаганнар.

Чүәкнең сыңарын таба алмыйча, җайдак кире әйләнеп кайткан. Билгеле инде, үгез бәйләгән урынында булмаган. «Бауны өзеп качкандыр, мөртәт!» — дип уйлаган ул һәм елга яры буйлап чаптырып киткән. Бераз чапкач, елгада агып баручы үгезне күргән. Тиз генә чишенгән дә, үгезне кот-

карам дип, суга сикергән бу. Йөзеп килеп, мөгезеннән эләктерсә, үгез урынына аның башы гына килеп чыккан, ди. «Бу үгез карагын тотып кирәгән бирмәсәм, якты дөнья йөзе миңа харам булсын!» — дип кычкырган җайдак һәм, ярга чыгып, киемнәре янына йөгергән.

Ләкин ул арада моның киемнәреннән дә, юртак атыннан да җилләр искән, ди. «Кеше малын алган — үзе коры калган», — дип такмаклый-такмаклый җайдак әле дә булса елга яры буйлап арлы-бирле чабып йөри, имеш...

ЭНҖЕ БӨРТЕГЕ

Вьетнам халык әкияте

Яшәгән, ди, Уа атлы ятим кыз. Аңа үзе кебек үк ярлы Го гашыйк булган. Кыз тамак хакына көне-төне байга бил бөккән. Бервакыт хуҗасы аңа дөге амбарын сакларга кушкан. Кыз суга дип күл буена төшкән икән, җылы җил исеп куйган. Күл өсте дулкынланып алган һәм аннан гаҗәеп матур күлмәк кигән гүзәл су кызы килеп чыккан. «Су патшасы кызы авырый,— дигән ул.— Аны син генә дәвалый аласың. Әйдә минем белән». Кыз Уаны күл төбенә алып төшкән. Су патшасы кызын яр буенда уйнаганда чикерткә тешләгән икән. Шуннан авырган.



Уа кызны үләннәр белән дәвалап бик тиз терелткән. Патша моңа шатланган һәм Уага тылсымлы энҗе бүләк иткән. Уаны ярга чыгарып куйганнар. Кыз амбар янына килсә, коты чыккан: кошлар, тиеннәр ярты дөгене ташып бетергәннәр, ди. Узып баручы бер авыл карты: «Хуҗаң бик ачулы. Сак бул!» — дип кисәткән.

Уа бик хәсрәтләнгән һәм кинәт энҗе бөртеген исенә төшергән. «Энҗе, энҗе, дөге бирче миңа, тамагым ачты!» — дип үтенгән. Кыз алдына затлы ризык тулы дастархан җәелгән, артында элеккесеннән өч тапкыр зуррак амбар калыккан.

Иртәгесен Уа хуҗасы бай янына килгән икән,

тегесе ырлап аңа ташланган. Ләкин кыз курыкмаган. «Мин сиңа үзеңнекеннән дә күбрәк дөге бирәм. Әмма моннан ары сиңа хезмәт итмәм!» — дигән.

Байның улы беләк буе пычак тотып кыз артыннан киткән. «Алдасаң, шундук чәнчеп үтерәм»,— дип янаган.

Уа энҗедән су кызыныкы кебек күлмәк сорап кигән. Бай улы шулчак Уаның гүзәл чәчәкләрдән дә гүзәлрәк икәнен күреп таң калган, теле тотлыккан. «М-ми-ңа дө-ге түгел, син кирәк, сиңа өйлә-нәм»,— дигән. Уа кычкырып көлгән. «Син котырган эттән дә эшәкерәк. Дөгеңне ал да үкчәңне күтәр»,— дигән. Бай малае моны атасына сөйләп биргән. Бай, гаскәрен җыеп, кызның йортын таларга җыенган. Ләкин авылдашлары Уаны кисәтеп өлгергәннәр. «Энҗе, безне явыз адәмнән сакла!» — дип үтенгән кыз. Шулчак бай йорты тирәли кыя-таулар калкып чыккан. Байның гаскәре тауны кичәргә күпме тырышса да булдыра алмаган. Уа белән Го исә хәзер дә рәхәттә яшиләр, ди.



ПАДИШАҺ ҺӘМ АГАЙ

Төрек
халык әкияте

Көннәрдән бер көнне Солтан Мәхмүт үз патшалыгы буйлап сәяхәт итәргә чыккан. Җәйге кояш кыздыра башлагач, әлсерәп, алмагач төбенә сузылып яткан бу. Шулчак агач башындагы бер алма туп-туры моның авызына өзелеп төшкән. Падишаһ алмагач хуҗасын чакырып китергән дә:

— Мин синең бер алмаңны ашадым. Инде менә бурычымны ничек итеп түләргә дә белмим. Әгәр син бер-бер бәлагә юлыксаң, туп-туры Истанбулга кил дә мине эзләп тап,— дигән.

Чыннан да, әлеге агайның башына кинәт кенә бәла төшә. Күршесе белән ике арада җир өчен

гауга чыга боларның. Эш судка барып җитә. Ләкин бу фәкыйрьне анда да яклаучы табылмый. Шулчак хатыны мондый киңәш бирә:

— Тот та Солтан Мәхмүт янына бар син. Бүләккә бер кәрҗин алма алырсың. Патша булып патша үзенең биргән вәгъдәсен бозмастыр, шәт.

Шулай итеп, агай Истанбулга юл тота. Эзли торгач, падишаһ Солтан Мәхмүт сараен да эзләп таба. Агайны ашаталар-эчертәләр, зиннәтле-затлы бүлмәдә урын җәеп яткыралар.

Мондый кадер-хөрмәткә күнекмәгән агай, йокыга китә алмыйча, бик озак боргаланып ята. Аптырагач, урамга чыгып кермәкче була. Шулчак агай каршына айбалталар тоткан сакчылар килеп баса. Кем икәнен, каян килгәнен сораша башлыйлар. Шиккә калган сакчылар моны эләктереп алалар да төрмәгә ябып куялар.



Өч ел вакыт узгач, падишаһ нишләптер кинәт кенә агайны искә төшерә, тиз генә үз янына чакыртып китерә.

— И минем хөкемдарым,— дип, җиргә тезләнә агай.— Сездән мин бары тик өч нәрсә: балта, бау һәм Коръән генә сорыйм... Беренче эш итеп балта белән алмагачны чабып аударам. Бәлагә тарыгач, хатыным бер кәрҗин алма биреп, Сезнең янга җибәрде. Моның өчен мин аны бау белән агачка асып куям. Авылыма кайткач, бөтен халык алдында Коръән тотып, патшадан игелек көтмәскә ант итәм.

Бу сүзләрдән куркып калган падишаһ агайга янчык тутырып алтын бирә, хәерле юл тели-тели, сарай капкасы төбенә хәтле озата чыга.



ХӘЙЛӘКӘР ӘТӘЧ

Болгар
халык әкияте



Әтәч киртә өстенә менеп баскан да, канатларын җәеп, бар көченә: «Кик-ри-күк!» — дип кычкырып җибәргән. Шулчак янәшәдәге куаклар арасыннан төлке килеп чыккан.

— Хәерле көн! — дип сәлам биргән төлке.— Тавышың бигрәк матур икән! Сине ишеткәч, мәрхүм әтиең искә төште... Менә ул җырлый иде, ичмасам!

— Әти ничек җырлый иде? — дип авызын ачкан әтәч.

— Бер аягы белән киртәгә баса да икенче аягын



канат астына кыстыра. Аннары бер күзен йомып, җырларга тотына иде.

— Мин дә алай җырлый беләм! — дигән дә яшь әтәч, күзен чытырдатып йомган, бер тәпиен канат астына яшергән.— Кик-ри-күк!

— Ә син бер аякта торган килеш ике күзеңне дә йомып җырлый беләсеңме соң? — дип елмайган төлке.

— Беләм! — дип масаеп кычкырган әтәч.

Яшь әтәч ике күзен тиң йомуга, төлке киртәгә сикереп менгән дә аны муеныннан эләктереп алган.



Аннары урман эченә кереп, әтәчне ашарга җыена башлаган.

— И-и-их! — дип авыр көрсенгән әтәч.— Синең мәрхүмә әниең болай итми торган иде...

— Ә ничек итә иде? — дип, башын күтәргән төлке.

— Әтәч ашар алдыннан әниең һәрчак дога укый торган иде. Бигрәкләр диндар иде шул мәрхүмә...

— Мин дә дога укый беләм! — дип мактанып кычкырган төлке һәм, алгы тәпиләрен җиргә куеп, күзләрен йомган да дога пышылдый башлаган.

Әтәчкә шул гына кирәк! Ул, төлкенең тәпиләреннән ычкынуга, канатларын кага-кага: «Кик-ри-күк!» — дип кычкырган да кетәклек ягына элдергән.

Шул көннән башлап төлкеләр дога укымый башлаганнар, ди.



МАЙМЫЛ БЕЛӘН ЧИКЕРТКӘ

Кытайдагы яо
халык әкияте



Борын-борын заманда киң басу уртасында яшәгән, ди, бер Чикерткә. Тау-таш арасында гомер итүче Маймыл аннан бик көнләшкән.

— Син бәләкәй, шуңа күрә сиңа тауда яшәү фарыз,— дигән ул көннәрдән бер көнне Чикерткәгә.— Басуда мин яшәргә тиеш.

— Мине әнием шушы басуда тапкан, шуңа күрә мин монда яшим. Бүтән җиргә китәргә җыенганым да юк,— дип карышкан Чикерткә.

— Алайса, көч сынашып карыйк. Кем җиңә — шул басуда яшәр,— дигән Маймыл.

Икенче көнне иртүк Маймыл үзенең дус-ишләрен җыеп басуга төшкән. Һәммәсенең кулында тәпәч икән боларның.



— Син кайда? Сугышырга вакыт! — дип дәррәү кычкырган маймыллар.

— Үләннәргә чык төшкән бит. Кояш күтәрелеп, чык кипкәнне көтегез,— дигән аларга Чикерткә.

Чык төш җиткәндә генә кибеп беткән. Кояшка карый-карый түземнәре төкәнгән маймыллар каршына, ниһаять, Чикерткә килеп чыккан. Килеп чыккан да иң алдагы маймылның борынына сикереп менеп тә кунган. Атаман Маймыл моны күреп алган да тәпәче белән кизәнеп китереп суккан.



Сугуы булган, маймыл тәгәрәп җан да биргән. Ул арада Чикерткә икенче маймылның борынына кунган. Атаман саллы тәпәче белән тагын кизәнгән... Шулай итеп Чикерткә, бер маймылдан икенчесенә очып куна-куна, маймылларны бер-бер артлы җиргә аудара торган. Иң ахырда бәхәс башлаган Атаман Маймыл гына исән калган.

— Ничек соң? Кайсыбыз көчле? — дип сораган аннан Чикерткә.— Инде басуга күчәргә исәбең юкмы?

— Син җиңдең, басуда син яшәргә тиеш,— дигән аңа Маймыл.

Әле дә булса Чикерткә — басуда, Маймыл тау-таш арасында гомер итеп яталар, ди.

ҚАБАРТМА

Норвег халык әкияте



Бер хатынның эреле-ваклы җиде баласы булган. Хатын, камыр басып, кабартма пешерергә куйган. Өйгә хуш-ис таралган. Җиде бала, җиде яктан килеп, әниләреннән кабартма сорарга тотынганнар. «Сабыр итегез, оланнарым,— дигән ана,— бераз өсте генә килсен, сезнең җидегезгә дә, бабагызга да өлеш чыгарырмын». Моны ишеткәч, кабартманың коты алынган, һәм ул, табадан сикереп, тәгәрәп киткән.

Әнисе, бабасы, җиде бала кабартманы куа чыкканнар. Қабартмадан җилләр искән! Тәгәри торгач, аңа урманчы агай очраган. «Қил әле, тәмле







кабартма, ашап куйыйм үзеңне»,— ди икән бу. Қабартма көлгән генә: «Уңган анадан, кыбырсык бабайдан, такылдавык балалардан качтым мин. Сиңа гына тоттыраммы соң?!» Тагын тәгәрәп киткән бу. Кызыл кикрик әтәчкә, тавыкка, үрдәккә очрап, алардан котылган. Аннары ата казга тап булган. Аңа да шул ук җавап: «Уңган анадан, кыбырсык бабайдан, такылдавык балалардан, урманчы агайдан, акыллы баш тавыккайдан, кызыл кикрик әтәчкәйдән, үрдәккәй-түгәрәккәйдән котылдым, синнән генә тоттырмам инде».







Озак тәгәрәгән кабартма. Ниһаять, моңа дуңгыз очраган. «Әз генә туктап торчы, кабартма, туйганчы карыйм үзеңә,— дигән ул.— Әнә, урманны күрәсеңме? Әйдә, бергәләп узыйк аны. Икәү булгач, курыкмабыз». Җитәкләшкән дә киткән болар. Бара торгач, юлларын елга бүлгән. Елга кечү дуңгызга берни түгел, йөзә дә чыга, ә кабартмага кыенрак. «Утыр танавыма,— дигән дуңгыз.— Мин сине елга аша алып чыгам. Су тисә, төсең китәр».

Қабартма риза булган. «Тырт» итеп дуңгызның танавына сикерүе булган, тегесе — һап, кабып та йоткан.

СЫРНЫ НИЧЕК БҮЛГӘННӘР?

Африка
негрлары әкияте



Ике мәче сыр урлаганнар. Берсе аны үзе бүлмәкче булган, ләкин икенчесе аңа ышанмаган.

— Юк, судья итеп маймылны чакырыйк, ул бүлсен,— дигән. Маймыл риза булган. Үлчәү белән пычак китерткән һәм сырны, бер кисәген зуррак итеп, икегә бүлгән. Аларны үлчәп карагач, тигез бүленмәгән икән, дип, зур кисәктән бер кабым тешләп алган.



— Нишлисең син?! — дип кымыржыганнар мәчеләр.

— Икегезгә дә тигез булсын өчен зуррагыннан бераз өзеп каптым әле,— дигән маймыл.

Хәзер инде икенче кисәк зуррак булып калган. Маймыл анысыннан да өзеп капкан. Мәчеләр маймылның аларны сырсыз калдырырга маташуын төшенгәннәр.

— Судья әфәнде, калган сырны булса да безгә кире бирегез, үзебез бүләрбез,— дип ялварганнар.

— Юк, юк! — дип кычкырган маймыл.— Сыр бүлгәндә бәхәсләшеп, сугышып китүегез бар. Аның өчен җәнлекләр патшасы алдында мин җавап бирәсе ич!

Маймыл әле бер кисәкне, әле икенчесен тешләп каба-каба, сырны бик тәмләп ашап куйган. Соңгы валчыгын кабып йоткач, мәчеләргә акыл биргән:

— Ярый, барыгыз. Хәерле юлда йөрегез. Аңыгызны беркайчан да комсызлык томаламасын,— дигән.

ҠЕРПЕ

Литва
халык әкияте



Юл буйлап йөгереп килгәндә, керпе бакыр бер тиен тапкан. Нәкъ шулчак янәшәдә генә фаэтонга утырып бай әфәнде узып бара икән. Керпе аны күреп алган да, бакыр бер тиенен күрсәтеп, кычкырырга тотынган:

— Минеке бар, ә байныкы юк! Минеке бар, ә байныкы юк!

Байның моңа бик тә кәефе киткән. Ул, кучерның җилкәсенә төртеп, атны туктатырга кушкан.

— Нәрсә ул тагын: синдә бар, ә миндә юк? — дип җикергән бай.



— Бакыр бер тиен! — дигән керпе һәм байга күрсәткән. Байның ачуы чыккан, ул кучерга керпенең бер тиенен алырга кушкан.

— Алайса, чыннан да, синең бер тиенең дә юк! — дип көләргә тотынган керпе.— Булса, минекен алмас идең.

Моны ишеткәч, бай бөтенләй чыгырдан чыккан. Бакыр бер тиенне алган да юлга ыргыткан.

— Сукыр бер тиенең белән кадалып кит! Бик кирәге бар иде! — дигән ул. Ә керпе һаман кетекете көлә икән:

— Курыкты! Курыкты! Миннән курыкты да бер

тиенне кире ташлады. Бай миннән курыкты, дип хәзер бөтен халыкка сөйлим!

Шулчак бай ярсып фаэтоннан сикереп төшкән дә керпе өстенә ташланган.

— Хәзер ничек курыкканымны күрсәтәм мин сиңа! — Эләктереп алам дип кулын гына сузуы булган, керпе йомарланып энәләрен тырпайтып куйган. Бар — кагылып кара син аңа!

— Ярар,— дип бармак янаган бай,— акылга утыртырмын әле мин сине!

Шулай дигән дә фаэтонга утырып ары китеп барган.

Ә керпе юл уртасына баскан килеш бии-бии такмаклый икән:

— Бай әфәнденең корсагы зур, башы бәләкәй! Бай әфәнденең корсагы бар, акылы юк!

Шулай итеп, керпе ахмак байдан бер рәхәтләнеп көлгән, ди.



ҮГЕЗ КҮЗЛӘРЕ

Кытай
халык әкияте



Кайчандыр карурманда бик куркыныч бер җанвар яшәгән. Аны күрүгә, урман халкының коты оча икән. Кемне очратса да, очлы мөгезләрен чайкый-чайкый үкерергә тотына, тояклары белән җирне актара, күзен-башын акайтып өстеңә ташланырга гына тора, ди.

«Нинди җанвар икән ул?» — дип уйлыйсыздыр инде. Без җигеп йөри торган юп-юаш, күндәм буйвол! Нигә шулкадәр усал булган соң, дисезме? Сер итеп кенә әйтәм: бөтен хикмәт күзләрендә аның. Нәрсәгә генә караса да, аңа бөтенесе бәләкәйләнеп күренә икән. Юлбарыска карый — песи



күрә. Песигә карый — тычкан күрә. Оп-олы кешегә карый — сабый бала күрә.

Шундый күзләре була торып, кемнән курыксын инде ул?!

Көннәрдән бер көнне буйвол үзен җәнлекләр патшасы дип игълан итәргә булган. Моны ишеткәч, урман халкы ду купкан. Алар яшеренеп кенә тын аланда киңәшмә җыйганнар һәм анда буйволны күзләреннән мәхрүм итәргә карар чыгарганнар.

Ләкин буйволны бөтенләй сукыр калдырып та булмый ич инде. Уйлаганнар-уйлаганнар да иң

юаш җан иясе — казның күзләрен буйволныкына алыштырырга булганнар.

Шулай бер төнне йоклап яткан буйвол белән казның күзләрен тычкан шыпырт кына алыштырып та куя.

Уянып китә буйвол. Күзләрен ачып караса, тычкан урынына песи чаба, ә тычкан артыннан чапкан мәче аңа юлбарыс булып күренә, ди.

Шул көннән башлап буйвол юп-юаш эш үгезенә әйләнеп кала. Кеше аны җигеп көне-төне эшләтә башлый. Барысына да түзә буйвол. Беркемгә дә тими, беркемне дә куркытмый. Авыл малайлары өстенә менеп атланса да сүз дәшми.

Ә ата каз танымаслык булып үзгәрә. Буйвол күзләре белән карагач, аңа урмандагы бар нәрсә кеп-кечкенә булып күренә. Ул үзен дөньяда иң көчле җанвар дип уйлый. Каршысына кем килеп чыкса да, канатларын җәеп, муенын сузып, ысылдый-ысылдый ташланырга гына тора.

Әйдә, ысылдый бирсен лә! Барыбер курыкмыйлар ич аннан. Күпме ысылдаса да, ата каз үгез була алмаячак.

ЯЛКАУ МАЛАЙ ҺӘМ ЧЫПЧЫК

Хакас
халык әкияте

Бер ялкау малай җәйге челләдә елга ярында юкны бушка аударып утыра икән. Утыра торгач, су коенасы килә башлаган моның. Ләкин ул, чишенергә иренеп, ниятеннән кире кайткан. Шул вакыт агач башындагы чыпчык такмаклый-такмаклый чыркылдарга тотынган:

— Тирләп-пешеп беткәнсең ич. Су коенып алыр идең...

— Әйтүе генә ансат,— дип җавап биргән малай.— Әгәр суда бата башласам, кем коткарыр мине?

— Яр буендагы талга тотынырсың.

— Әйтергә ансат ул. Әгәр кулымны авырттырсам?

— Бияләй ки алайса,— дип көлгән аннан чыпчык.

— Бияләем чыланса? — дип авызын турсайткан малай.

— Кояшта киптерерсең.

— Әгәр бияләй ботакка эләгеп ертылса?

— Ямарсың.

Чыпчык, малайның баш очында бөтерелә-бөтерелә, чыркылдавында булган. Ялкау малай исә,

яр буенда кырын яткан килеш, авыз эченнән генә һаман мыгырдана икән:

— Ямаганда энә белән бармакка кадасам?

— Уймак кисәң, кадамассың.

Чыпчыкның үрти-үрти чыркылдавы малайны тәмам чыгырыннан чыгарган.

— Әле һаман акыл өйрәтәсеңме! — дип кычкырган ул һәм аяк астындагы бер ташны алып чыпчыкка томырган.

Кизәнеп ыргытканда аягы таеп, малай елгага барып төшкән. Чыпчык пырылдап очып киткән.

Малай судан чыгып, тагын яр буена сузылып яткан. Үзе кояшта кызына, үзе һаман чыпчыкны каргый икән.

ЭТ, МӘЧЕ ҺӘМ ТЫЧКАН

Чех
халык әкияте

Күп еллар элек бар җәнлек-җанварларның хуҗасы — Кеше этне ярдәмче итеп алуы турында карар чыгарган. Этләр моңа бик тә сөенгәннәр, мәчеләр исә көнләшүдән шартлый язганнар. Көннәрдән бер көнне мәчеләр, киңәшмә җыеп, этләрнең бу хокукын үзләренә алырга булганнар. Күп уйлап тормыйча, этләргә хокук бирү турында язылган пергаментны урлап, келәттәге иске-москы арасына яшереп куйганнар.

Келәттә яшәүче тычкан моны күреп алган да дус-ишләрен җыйган. Билгеле инде, тычканнарның



да әлеге хокукны үзләренә аласы килгән. Ахырдан иң карт, акыллы тычкан болай дигән:

— Туганнарым! Безнең өчен бердәнбер юл бар: бу хокук кәгазен ашарга кирәк. Шулай итсәк кенә, аны без фәкыйрьләрдән беркем дә тартып ала алмаячак.

Күз ачып йомганчы тычканнар пергаментны ашап та бетергәннәр.

Көннәрнең берендә этләр әлеге карарны халыкка җиткермәкче булганнар. Шулчак хокукны саклаучы эт ык-мык итә башлаган. Тик соңыннан барыбер пергаментны мәчеләр урлаганын әйтергә







мәҗбүр булган. Ярсыган этләр өерләре белән мәчеләр өстенә ташланганнар, югалган хокукларын таптыра башлаганнар. Куркудан мәчеләр дәррәү келәткә ябырылганнар. Күпме генә эзләсәләр дә, алар хокук кәгазен таба алмаганнар — пергаменттан җилләр искән! Моның тычканнар эше икәнен мәчеләр шундук сизенгәннәр, билгеле. Ләкин күпме генә ялварсалар да, тычканнар хокук язуын бирмәгәннәр.

Шушы вакыйгадан соң этләр мәчеләрнең кан дошманына әверелгән. Үз чиратында мәчеләр дә тычканнардан мәңге үч алырга ант иткәннәр.



ЯҢГЫР ЯУГАН ТӨНДӘ

Төркмән
халык әкияте

Яхшы киемнәр киенгән берничә кеше байга кунакка бара икән. Кәминә боларны күреп алган да артларыннан ияреп киткән. «Бу сәләмәләрең белән кая бармак буласың? Безнең дәрәҗәне төшереп, кеше көлдереп йөрмә!» — дип, аны байның ишеге төбеннән төрткәләп куып җибәргәннәр.

Йорты-җире, сыенып урыны булмаган Кәминә урам уртасында басып калган. Озак уйлап тормыйча, ул каршыдагы фәкыйрь генә йортның ишеген шакыган. «Рәхим ит! Түрдән уз! — дип каршы алганнар аны.— Сыйларга сыебыз булмаса да, күңелебез киң, урыныбыз иркен...» «Төн кундырып

чыгарсагыз, мең рәхмәт!» — дигән Кәминә. Шул арада хуҗа хатынының казан тирәсендә кайнашуын күреп алган. Үзе казанны болгата, ә аш китерергә җыенганы сизелми икән моның. Балалар еламсырап йөргәннәр-йөргәннәр дә йокларга ятканнар. Кәминә түзмәгән, хуҗага сүз каткан. «И кунак, син безнең иң авырткан җиргә кагылдың,— дигән хуҗа.— Алар ашарга сорый, ә безнең бер бөртек ризыгыбыз да юк. Кич җиттисә, мин казанга су белән таш салам, хатыным шуны болгатып тора. Аннары сабыйларны: «Ятыгыз сез, аш пешүгә уятырмын»,— дип алдый-алдый йоклатам».

Бу сүзләрне ишеткәч, Кәминәнең йөрәгенә кан саугандай була. Өйдәгеләр йокыга талгач, ул әкрен генә урамга чыга да байның бер сарыгын җитәкләп алып килә. Аны тиз генә суеп, хуҗа хатынына кертеп бирә. «Менә, сеңлем, балаларыңа пешереп ашат»,— ди ул аңа. Балалар тамакларын туйдырып йокларга яткач, ул комган ала да түбәдәге тишектән алар өстенә су чәчрәтә башлый. «Яңгыр ява»,— дип пышылдаша-пышылдаша, балалар йокыга киткәннәрен сизми дә калалар.

Иртән байга бер сарыгы югалганын җиткерәләр. «Теге хәерче эше бу»,— ди ул һәм Кәминә кунган йортка таба китә. Өй янында уйнап йөргән балалардан: «Ит ашадыгызмы?» — дип сорый. «Ашадык!» — дип чатлатып җавап бирә балаларның иң кечесе. «Кайчан?» — дип сорый бай. «Яңгыр яуган төнне». «Соңгы тапкыр моннан ярты ел элек, яз көне яуган иде яңгыр»,— дип уйлый бай һәм урам буйлап югалган сарыгын эзләп китә.

«ТАТАРТ» ҮЗӘГЕ

Әкиятләрне тәрҗемә итүче,
эшкәртүче һәм җыентыкны
төзүче РАЗИЛ ВӘЛИЕВ

Китап Җыен фонды — Татар телен, мәдәниятен саклау һәм үстерү фонды, аның янындагы «Татар» үзәге тарафыннан басмага әзерләнде һәм нәшер ителде

Нәшер өчен җаваплылар **Р. Вәлиев, М. Госманов, Ә. Кәримуллин, Р. Сираҗиев, Ф. Хәмидуллин**

Чыгарылыш өчен җаваплы
РӘШИТ БАГАУТДИНОВ

Кече яшьтәге мәктәп балаларына

САМАЯ ДЛИННАЯ СКАЗКА

Сказки

(на татарском языке)

Редакторы *Ф. Зыятдинова*
Художество редакторы *А. Тимергалина*
Техник редакторы *Н. Зәйнуллина*
Корректоры *С. Мифтахова*

Җыярга тапшырылды 25.03.93. Басарга кул куелды 25.01.94. Форматы $60 \times 90^1/_8$. Офсет кәгазе № 1. «Литературная» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 2,0. Шартлы буяу-оттиск 8,0. Нәшер-хисап табагы 2,04. Тиражы 50 000 экз. Заказ П-84. Бәясе иреклә.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.

Татарстан республикасы Матбугат һәм информация министрлыгының Камил Якуб исемендәге полиграфия-производство берләшмәсе типографиясе. 420111. Казан, Бауман ур., 19.

ББК 82.3(0)
И 99

И $\frac{4803560104-007}{М132(03)-94}$ 168—93

ISBN 5—298—00347—8

© Татарстан китап нәшрияты, 1994